ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　КАРАР

_______________　　с. Верхний Услон　　_______________

«Муниципаль торак фондының торак урыннарын милеккә тапшырганда документлар рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Югары Ослан муниципаль районында муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры" дәүләт мәгълүмат системасы турында" 2010 елның 02 декабрендәге 880 номерлы карарына үзгәрешләр кертелүгә бәйле рәвештә, "Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында" 2010 елның 10 сентябрендәге 729 номерлы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан "Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры" дәүләт мәгълүмат системасы турында" 2011 елның 23 декабрендәге 961 номерлы карарларны кабул итүгә бәйле рәвештә, Югары Ослан муниципаль районының башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Муниципаль торак фондының торак урыннарын гражданнар милкенә тапшырганда документлар рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын» расларга.

2. «Югары Ослан муниципаль районында муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 15 августындагы 1093 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны социаль-икътисадый үсеш буенча башкарма комитет җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Л.С. Хәкимҗанов

О.И.Замалдинова
2018-348